**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мәлбагыш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Мәлбагыш авылы № 74 24 ноябрь 2017 ел

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

Җирле үзидарә турында федераль һәм республика законнарындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә

Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карар проектын (1 нче кушымтаны) кабул итәргә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http:// aznakyevo.tatarstan.ru.
3. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Мәлбагыш авыл җирлеге карары проекты буенча 2017 елның 18 декабрендә 16.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча гавами тыңлаулар үткәрергә: Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мәлбагыш авылы, Җәлил ур., 4 йорт.
4. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин: Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мәлбагыш авылы, Нефтьчеләр ур., 30 йорт.
5. Гавами тыңлаулар уздыру буенча составта эшче төркем төзергә:
- Әхтәмова Илмира Абүзәр кызы-Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгы;
- Әхмәтшин Мансур Әсмәндияр улы- Мәлбагыш авыл җирлеге депутаты;
- Әхмәтшин Рөстәм Мөфәздәл улы- Мәлбагыш авыл җирлеге депутаты
6. Гавами тыңлаулар үткәрү буенча эшче төркемгә «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне, гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне, исәпкә алуны тәэмин итәргә.
7. Законлылык һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә гавами тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырышка карауга кертергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.А.Әхтәмова